ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**12.03.2021**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№497**

Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 27 июлендәге 1565 номерлы карары белән (2016 елның 25 июлендәге 1940 номерлы, 2018 елның 23 октябрендәге 2155 номерлы, 2019 елның 16 апрелендәге 889 номерлы карарлар керткән үзгәрешләр белән) расланган, җир эшләрен җитештерүгә ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын актуальләштерү максатларында һәм «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 02 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 28 мартындагы «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 437 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсенең, Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсе 2020 елда Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын үтәүнең көтелгән нәтиҗәләре һәм республиканың финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча 2021 елның 04 гыйнварындагы ПР-3 номерлы уртак коллегия беркетмәсен үтәү йөзеннән, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетының 2015 елның 27 июлендәге 1565 номерлы карары белән (2016 елның 25 июлендәге 1940 номерлы, 2018 елның 23 октябрендәге 2155 номерлы, 2019 елның 16

апрелендәге 889 номерлы карарлар керткән үзгәрешләр белән) расланган, җир эшләрен җитештерүгә ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6 пунктының «Стандартка таләпләр эчтәлеге» 2 нче графасына түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«(3) гариза бирүченең салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмау (барлыгы) турында белешмә, авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш».

1.2. 2.8 пунктының «Стандартка таләпләр эчтәлеге» 2 нче графасына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«(5) мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булуы».

1.3.4.1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«(3) гариза бирүченең салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булмау (барлыгы) турында белешмә, авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш».

1.4. Административ регламентның 1 нче кушымтасында соңгы абзацны яңа редакциядә бәян итәргә: «Сорату рәвешендә алынган скандокументларның оригиналларын бирүне үземә йөклим. 2006 елның 27 июлендәге «Шәхси мәгълүматлар турында» 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә (җыюга, системага салуга, туплауга, таратуга (шул исәптән тапшыруга) һ.б.) ризалыгымны бирәм».

2. Әлеге карарны Зеленодольск муниципаль районы Советы Аппаратының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге начальнигы Р.З.Хаҗиевка «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче И.Р. Ганиев